**Латыйпов, Рәмис** «Кара китап»: Америка өрәңгесе / Р. Латыйпов. - Текст : турыдан-туры // Шәһри Чаллы. – 2019. – №5 (25 январь). – С.6.
***Төп сүзләр:** – Татарстан Республикасы – Куркыныч тудырган үсемлекләр – «Кара китап» – Америка өрәңгесе – Экология*




АМЕРИКА ӨРӘҢГЕСЕ САЛКЫНГА ЧЫДАМ. УЛ ОРЛЫК ЧӘЧЕП ТАРАЛА. ҮСЕНТЕСЕ 6-7 ЕЛДА ОРЛЫК БИРЕРЛЕК ДӘРӘҖӘДӘ ҮСЕП ҖИТӘ. ЧӘЧӘК АТКАНДА СЕРКӘЛӘРЕ КЕШЕДӘ АЛЛЕРГИЯ УЯТЫРГА МӨМКИН. КОЕЛГАН ЯФРАКЛАРЫ БҮЛЕП ЧЫГАРГАН МАТДӘЛӘР БАШКА АГАЧЛАРНЫҢ ҮСЕШЕН ТОТКАРЛЫЙ. ГАЛИМНӘР ФИКЕРЕНЧӘ, ЮЛ БУЕНДА ҮСКӘН АГАЧЛАР АВТОМОБИЛЬЛӘР ҺАВАГА ЧЫГАРГАН ГАЗНЫ ТАГЫН ДА КҮБРӘК ОКСИДЛАШТЫРА.

# «КАРА ИТАП»:
# Америка өрәңгесе

**Рәмис ЛАТЫПОВ**

Казан галимнәре төзи башлаган «Татарстанның Кара китабы»на кергән үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итәбез. Бу юлы сүзебез - Америка өрәңгесе турында. Әлеге агач безнең республика гына түгел, бөтен Россиянең үсемлекләр дөньясына куркыныч тудыра. Экологик системага зыян китерә торган 50 инвазив үсемлек арасына керә.

Корычагач (ясень) яфраклы өрәңге агачының туган ягы Төньяк Америка булганга аны Америка өрәңгесе дип атыйлар. Европага экзотик агач буларак XVII гасырда, Россиягә XVIII гасыр азакларында кертелә. XX гасыр башларында инде ул ботаника бакчаларыннан «качып», җирле табигатьтә таралып, үрчергә тотына.

- Торак пунктларны яшелләндерү максатында аны узган гасырның 60нчы елларында күпләп утырткannар. Ул тиз үсә, талымсыз, карарга, тәрбияләргә кирәкми. Ташландык җирләрдә үзе дә үрчи башлый. Су буйларындагы әрәмәлекләр Америка өрәңгесеннән аеруча зур зыян күрә. Елга буйларында элек тал, имәннәр үссә, хәзер өрәңге әлеге җирле агачларны кысрыклап чыгара башлады. Кайбер кечкенә елга буйларында хәзер өрәңгедән башка агач юк та. Мәсәлән, Алабуга янында - Түбән Кама милли паркында бары тик өрәңге генә үсә торган урын бар. Елга буендагы агачлыкта зур агачлар - өрәңгеләр, яшь үсентеләр, чирәм урынына - өрәңге шытымнары. Ягъни тулысынча шушы килмешәктән торган табигый бергәлек барлыкка килгән, - дип сөйләде КФУның Гомуми биология кафедрасы доценты **Вадим Прохоров.**

## ЭНЕРГИЯ ТАПШЫРУ ЧЫЛБЫРЫ ӨЗЕЛӘ

Игътибар итсәк, су буендагы өрәңгеләргә кошлар оя кормый. Галимнәр моны туклану чылбыры өзелгәнгә дип аңлата. Шуңа күрә анда җан ияләре - кошлар, бакалар юк.

Инвазив, ягъни паразит үсемлекләрнең зыяны шунда, алар табигый бергәлекне юкка чыгарып, кеше яши торган мохитне тулысынча үзгәртергә мөмкин. Мәсәлән, безнең җирлектә меңләгән- миллионлаган еллар буена формалашкан урманнар да, болыннар да калмаячак. Җирле флора һәм фауна юкка чыгып, кешенең әлеге килмешәк үсемлекләр арасында калу куркынычы бар.

Вадим Прохоров сүзләренчә, кояш яктырта, үсемлекләрдә фотосинтез процессы бара, алар һавадагы азотны азыкка әйләндерә, әлеге үсемлекләрнең яфракларын бөҗәкләр ашый, кошлар һәм бакалар бөҗәкләр белән туклана. Алары, үз чиратында, башка җан ияләре өчен азык булып тора.

Америка өрәңгесенең яфракларын ашаган, гомумән, аларның үсү-үрчүенә куркыныч тудыр? торган бөҗәкләр юк. Нәтиҗәдү ул рәхәтләнеп үрчи, җирле үсемлекләр белән үзара көндәшлектә җиңеп чыга. Әгәр бездә яфраклары беркемгә дә кирәкмәгән үсемлекләр үрчи икән, энергия тапшыруның тулы бер чылбыры өзелә дигән сүз. Өрәңге белән тукланучы бөҗәкләр юк. Шуңа күрә әрәмәлектән башта - бөҗәклор, аннары - алар белән тукланган кошлар, аннары инде башкалары юкка чыга.

Бүгенге көндә өрәңгегә каршы көрәш чаралары юк, ди галим. Аннан кисеп кенә котылып булмый.

- Агачны кисү - проблемадан чыгу юлы түгел. Беренчедән, бу мәйданнар бик зур: кыйммәткә төшә, су буйларында техника белән эшләү уңайсыз. Ә өрәңгенең үрчү тизлеге шулкадәр зур - кишәрлекнең бер башына барып җиткәндә, без кисеп үткән урында яңа үсентеләр баш төртәчәк. Әрәмәлекне ел саен кисеп тору мөмкин эш түгел, - ди Вадим Прохоров.